**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Трудолюбово авыл җирлеге башкарма комитеты**

**КАРАР**

**№5** **« 25 » 02. 2016 ел**

**«Административ җәзага хөкем ителгән затларны мәҗбүри эшләр рәвешендә үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен раслау турында»**

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы президиумының « Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эш төрләрен билгеләү , аларга административ җәза мәҗбүри эшләр рәвешендә билгеләнгән төзәтү , аларның җәмгыять нормаларына, кагыйдәләренә , җәмгыятькә карата ихтирамлы мөнәсәбәтен формалаштыру максатларында мәҗбүри эшләрнең төрләрен билгеләү турында " 2012 елның 16 декабрендәге ПР-43-6 номерлы Карарын үтәүдә – Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турындагы кодексының 32,13 статьясы нигезендә һәм мәҗбүри эшләрнең , законлы көченә кергән суд карары буенча административ җәзаны үтәү рәвешендә мәҗбүри хезмәт дип саналуын исәпкә алып , Трудолюбово авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар кабул итте:

1.Трудолюбово авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләрне башкару урыннарын билгеләргә :
Трудолюбово, Культура, Алга, Октябрь, Котловка һәм И.Өченче Интернационалның җинаять – башкару инспекцияләре белән килешү буенча.

2. Мәҗбүри эш төрләрен билгеләргә: торак пунктларны һәм зиратларны төзекләндерү һәм яшелләндерү , юл буендагы куакларны кисү , елгалар һәм буалар территориясен чистарту, җинаять-башкару инспекцияләре белән килешү буенча карны җыю.
3. Әлеге карарны Аксубай районы буенча ФКУ филиалы белән берлектә Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкару инспекциясе тарафыннан төзәтү яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән һәм Трудолюбовский авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд хөкемнәрен үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.
4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбовский авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында да.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Трудолюбово авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе : Р.К. Кәнәфин